РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.06.2021 № 799-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “2021 елда халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар турында” 2020 елның 15 декабрендәге 1729-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 28 июнендәге 506 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “2021 елда халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар турында” 2020 елның 15 декабрендәге 1729-п номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы буенча 2021 елга халык өчен, социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннан файдаланган (наемга алган өчен түләү), торак урынны карап тоткан өчен түләү күләменә, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак бина милекчеләре өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләменә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“

| № п/п | Түләү атамасы | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | 2021 елның 1 гыйнварыннан хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тариф, сум. | 2021 елның 1 июленнән хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тариф, сум |
|---|---|---|---|---|
| ***Торак хезмәтләре*** | | | | |
| 1 | Торак бинаны капиталь ремонтлау | айга бинаның гомуми мәйданының 1 кв.м.нан | 6,11 | 6,38 |
| 2 | Торак фонды белән идарә итү | айга бинаның гомуми мәйданының 1 кв.м.нан | 2,20 | 2,20 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Торак бинага ремонт ясау һәм территорияне төзекләндерү | айга бинаның гомуми мәйданының 1 кв.м.нан | 2,57 | 2,62 |
| | Ишегалдын карап тоту (җәйге чорда үләннәрне һәм чүп үләннәрен чабу) | айга бинаның гомуми мәйданының 1 кв.м.нан | 0,28 | 0,31 |
| 4 | Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен карап тоту һәм аларга ремонт ясау: | | | |
| | сүүткәргеч-канализация челтәрләре | айга бинаның гомуми мәйданының 1 кв.м.нан | 1,91 | 1,91 |
| | үзәк җылылык бирү челтәрләре | айга бинаның гомуми мәйданының 1 кв.м.нан | 2,24 | 2,24 |
| | электр белән тәэмин итү челтәрләре | айга бинаның гомуми мәйданының 1 кв.м.нан | 1,05 | 1,08 |
| | төтен-вентиляция каналларын тикшерү (карау) | айга бинаның гомуми мәйданының 1 кв.м.нан | 0,34 | 0,35 |
| | Домофонның даими эшләвен тәэмин итү | айга бинаның гомуми мәйданының 1 кв.м.нан | 0,29 | 0,31 |
| 5 | Фасад газүткәргечләрен карап тоту һәм аларга ремонт ясау | айга бинаның гомуми мәйданының 1 кв.м.нан | 0,26 | 0,27 |
| 6 | Торак урынын наемга алган өчен түләүнең иң чик ставкасы | айга бинаның гомуми мәйданының 1 кв.м.нан | 30,24 | 31,53 |

“.

2. Әлеге карарны «Саба таңнары» район газетасында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары - икътисад бүлеге начальнигы М.М. Баһмановка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М. Р. Ишниязов